# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баек авыл җирлеге Яңа Сәфәр авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

24 ноябрь 2023 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 нчы матдәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 нче матдәсе нигезендә, түбәндәге сорау буенча 2023 нче елның 23 нче ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез, 2024 нче елга, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Яңа Сәфәр авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 (бер мең ) сум күләмендә, I-II төркем инвалидлар, Афганстандагы һәм башка локаль конфликттагы сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге бүлекләрдә укучы студентларга 500 (биш йоз) сум күләмендә һәм ЛНР һәм ДНРда махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны, шулай ук тормыш иптәшен (хатынын), балигъ булган балаларны, ә алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итеп, билгеләнгән үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

1). Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланууда булган автомобиль юлларын карап тоту:

- кышкы чорда Яңа Сәфәр авылы эчендэге урам юлларын карап тору;
- җәйге чорда Яңа Сәфәр авылы эчендэге урам юлларын карап тору;
- Яңа Сәфәр авылы торак пунктының урам юлларын төзекләндерү, вак таш һәм гравий белән тигезләү;
- Яңа Сәфәр авылы торак пунктының юллары кырындагы үләннәрне чабу;
- кар чистартуга килешү буенча хезмәтләр өчен түләү.

2). Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

- Яңа Сәфәр урамнарына гидрантлар урнаштыру

3). Урам яктырту челтәрләрен төзекләндерү:

- Яктырткычлар сатып алу, төзекләндерү, яктырткычларны алыштыру, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү һәм урам яктыртуга тотылган электр энергиясе өчен түләү.

4). Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү:

- Чишмәләр төзү, төзекләндерү һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү, үләннәрне чабу.

5).Халыкның күплэп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү:

- Сабантуй паркын төзекләндерү өчен материаллар алу;
- массакүләм ял итү урыннарында үлән чабу;

6). Традицион җирләү урыннарын төзекләндерү:

- зират коймаларын яңарту, төзекләндерү;
- зиратлардан каты көнкүреш калдыкларын чыгару.
- традицион күмү урыннарын чабу
- Бөек Ватан сугышында катнашып һәлак булучыларның исемнәре язылган табличкалар урнаштыру;
- инстументлар һәм кирәк - яраклар сатып алу

7). Яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту:

- Сулык янында куакларны кисү һәм чистартып түгү;
- чүп-чарларны чистартып түгү.

8). Су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манарасын һәм су белән

тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче скважиналарны проектлау, төзү һәм ремонтлау:

- Яңа Сәфәр авылы сүүткәргеч челтәрен ремонтлау;
- территориядәге чүп үләннәрен чабу;
- Яңа Сәфәр авылында эчәр суның сыйфатын лаборатор тикшерүләр үткәрү;
- су күтәрү насосының электр энергиясе өчен түләү;

«РИЗА» - «КАРШЫ»-

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 30 кеше кертелде, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 20кеше, бу 66,6% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

Гражданнар җыенында катнашкан 17 кеше «РИЗА» позициясе өчен, 3 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ**:

1.Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегенең Яңа Сәфәр авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

2. 2024 нче елда Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Яңа Сәфәр авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1 000 (бер мең) сум күләмендә,I-II төркем инвалидлар, Афганстандагы һәм башка локаль конфликттагы сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә һәм ЛНР һәм ДНРда махсус хәрби операция кысаларында мобилизацияләнгән һәм контракт нигезендә хезмәт итүче гражданнарны, шулай ук тормыш иптәшен (хатынын), балигъ булган балаларны, ә алар булмаганда, әлеге гражданнарның ата-аналарын үзара салым түләүдән азат итергә.

3. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1). Җирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган автомобиль юлларын карап тоту:

- кышкы чорда Яңа Сәфәр авылы эчендәге урам юлларын карап тору;
- җәйге чорда Яңа Сәфәр авылы эчендәге урам юлларын карап тору;
- Яңа Сәфәр авылы торак пунктының урам юлларын төзекләндерү, вак таш һәм гравий белән тигезләү;
- Яңа Сәфәр авылы торак пунктының юллары кырындагы үләннәрне чабу;
- кар чистартуга килешү буенча хезмәтләр өчен түләү.

2). Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:

- Яңа Сәфәр урамнарына гидрантлар урнаштыру

3). Урам яктырту челтәрләрен төзекләндерү:

- Яктырткычлар сатып алу, төзекләндерү, яктырткычларны алыштыру, килешү буенча хезмәтләр өчен түләү һәм урам яктыртуга тотылган электр энергиясе өчен түләү.

4). Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү:

- Чишмәләр төзү, төзекләндерү һәм алар янындагы территорияләрне төзекләндерү, үләннәрне чабу.

5).Халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау һәм аларга якын

территорияне төзекләндерү:

- Сабантуй паркын төзекләндерү өчен материаллар алу;
- массакүләм ял итү урыннарында үлән чабу;

6). Традицион җирләү урыннарын төзекләндерү:

- зират коймаларын яңарту, төзекләндерү;
- зиратлардан каты көнкүреш калдыкларын чыгару.
- традицион күмү урыннарын чабу
- Бөек Ватан сугышында катнашып һәлак булучыларның исемнәре язылган табличкалар урнаштыру;

Инстументлар һәм кирәк - яраклар сатып алу

7). Яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту:

- Сулык янында куакларны кисү һәм чистартып түгү;
- чүп-чарларны чистартып түгү.

8). Су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манарасын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче скважиналарны проектлау, төзү һәм ремонтлау:

- Яңа Сәфәр авылы сууткәргеч челтәрен ремонтлау;
- территориядәге чүп үләннәрен чабу;
- Яңа Сәфәр авылында эчәр суның сыйфатын лаборатор тикшерүләр үткәрү;
- су күтәрү насосының электр энергиясе өчен түләү;

4. Әлеге карарны ТР Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, ТР Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Баек авыл җирлеге башлыгы: М.Ф.Фахерлегаянов